**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге Советы КАРАРЫ**

2018 елның 19 ноябре 28№

Җирле референдум нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукы һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22 статьясы һәм 2018 елның 18 ноябрендә түбәндәге мәсьәләләр буенча узган референдумда тавыш бирү йомгаклары турында участок сайлау комиссияләренең беркетмәсе нигезендә, түбәндәге сораулар буенча:

"Чуаш Борнае авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2019 елда 600 сум күләмендә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, биш һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм 80 яшькә җиткән затлардан тыш, үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юллап, түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- яктырткычлар өчен кирәкле материал сатып алуга, кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнар түләүгә - 100 сум.

- урамдагы су белән тәэмин итү системасын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау, су челтәрләрен реконструкцияләү буенча проект-смета эшләрен башкару, кулланылган электр энергиясе өчен түләү, суны лаборатор-инструменталь тикшеренүләр өчен түләүгә-115 сум;

- поселок юлларын төзекләндерү һәм карап тоту (юлларны чистарту, чаптыру, кардан арындыру) - 300 сум;

- чүп-чар өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү һәм контейнерлар сатып алу, каты көнкүреш калдыклары полигонын рекультивацияләү, санкцияләнмәгән чүплекләр, белгеч эше өчен түләү - 85 сум.

Референдум нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Тавыш бирү тәмамланган мизгелгә референдумда катнашучылар исемлегенә 620 катнашучы кертелгән; референдумда тавыш бирүдә катнашучылар саны 542, бу 87,41% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Референдумда 523 катнашучы “Әйе” позициясе өчен тавыш бирде, бу 84,35 % тәшкил итә; “Юк” позициясе өчен 19 референдумда катнашучы тавыш бирде, бу 3,06 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча Чуаш Борнае авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны узган, ә референдум нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Чуаш Борнае авыл җирлегенең референдум йомгакларын расларга.

3. Үзара салым акчаларын түләү 18 яшькә җиткән, яшәү урыны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Чуаш Борнае авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, биш һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм 80 яшькә җиткән затлардан тыш, халыкка игълан ителгәннән соң 12 ай эчендә түләнә.

4.Әлеге карарны Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлегенең мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга.

Әлки муниципаль районы
Чуаш Борнае авыл җирлеге башлыгы: И.Г. Зарипов